**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№1716**
**12.03.2021**

Яр Чаллы шәһәренең «12 нче Олимпия резервы спорт мәктәбе» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешнең 4 пунктчасы, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 номерлы карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәт күрсәтүләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында нигезләмәнең 5 пункты, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 номерлы карары белән расланган муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәт күрсәтүләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең «12 нче Олимпия резервы спорт мәктәбе» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.
2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. 2018 елның 24 августында «Челнинские известия» газетасының 61 нче санында бастырып чыгарылган, 2018 елның 22 августында Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган «Яр Чаллы шәһәренең «12 санлы Олимпия резервы» махсуслаштырылган балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2018 елның 17 августындагы 4635 номерлы Башкарма комитет карары үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе                                                                                    Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 12 мартындагы
1716 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең «12 нче Олимпия резервы спорт мәктәбе»
муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан
күрсәтелә торган хезмәтләргә
тарифлар

| № т/с | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Бәясе |
|---|---|---|---|
| 1. | 2 | 3 | 4 |
| | Хезмәтнең исеме | | |
| 1. | Спорт залына абонемент (укучылар) | ай | 400,00 |
| 2. | Спорт залына абонемент (студентлар) | ай | 600,00 |
| 3. | Спорт залына абонемент (зурлар) | ай | 800,00 |
| 4. | Спорт залы хезмәтләре | сәгать | 75,00 |
| 5. | Массакүләм спорт чаралары оештыру һәм үткәрү | сәгать | 1 000,00 |

Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе
урынбасары, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе
башлыгы вазыйфаларын башкаручы А.Ф. Бареева